ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 19 февраль №192

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Шәһәр тибындагы Апас бистәсе” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Шәһәр тибындагы Апас бистәсе” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.2 пунктча өстәргә:

«12.2) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи;».

2.Әлеге карарны а Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

“Шәһәр тибындагы Апас бистәсе”
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Апас шәһәр җирлеге Советы рәисе А.Г. Җиһаншин